**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 9 и 10 Закона Республики Татарстан «О пожарной безопасности»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 апреля 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 18 мая 1993 года № 1866-XII «О пожарной безопасности» (в редакции Закона Республики Татарстан от 26 февраля 2005 года № 54-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1993, № 11-12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 2; 2006, № 7 (I часть); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I часть); 2013, № 5; 2014, № 6 (II часть); 2015, № 10 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I) следующие изменения:

1) часть третью статьи 9 изложить в следующей редакции:
«Иные гарантии правовой и социальной защиты работников противопожарной службы Республики Татарстан, за исключением оснований, условий и порядка обязательного государственного личного страхования, определяются Кабинетом Министров Республики Татарстан и не должны быть ниже существующих гарантий правовой и социальной защиты работников федеральной противопожарной службы.»;

2) статью 10 дополнить частями второй – четвертой следующего содержания:
«В случае гибели (смерти) работников противопожарной службы Республики Татарстан, наступившей при исполнении ими служебных обязанностей, либо их смерти, наступившей вследствие увечья (ранения, травмы, контузии) или заболевания, полученных ими при исполнении служебных обязанностей до истечения одного года со дня увольнения из противопожарной службы Республики Татарстан, выплачивается единовременное пособие в размере 3 000 000 рублей в равных долях

членам семей погибших (умерших) с последующим взысканием этой суммы с виновных лиц.

Членами семьи, имеющими право на получение единовременного пособия за погибшего (умершего) работника противопожарной службы Республики Татарстан, считаются:

супруга (супруг), состоящая (состоящий) на день гибели (смерти) в зарегистрированном браке с работником противопожарной службы Республики Татарстан;

родители работника противопожарной службы Республики Татарстан;

дети, не достигшие возраста 18 лет, или старше этого возраста, если они стали инвалидами до достижения ими возраста 18 лет, а также дети, обучающиеся в образовательных организациях по очной форме обучения, – до окончания обучения, но не более чем до достижения ими возраста 23 лет.

При досрочном увольнении работников противопожарной службы Республики Татарстан со службы в связи с признанием их негодными к службе вследствие увечья (ранения, травмы, контузии) либо заболевания, полученных ими при исполнении служебных обязанностей, им выплачивается единовременное пособие в размере 2 000 000 рублей с последующим взысканием этой суммы с виновных лиц.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
14 мая 2018 года
№ 33-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Янгын куркынычсызлыгы турында” Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләрен хокукый һәм социаль яклауның башка гарантияләре, мәҗбүри дәүләт шәхси иминләштерү нигезләреннән, шартларыннан һәм тәртибеннән тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, һәм алар янгынга каршы федераль хезмәт хезмәткәрләрен хокукый һәм социаль яклауның гамәлдәге гарантияләреннән ким булмаска тиеш.”;

2) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче – дүртенче өлешләр өстәргә:
“Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләре хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) очракта яки алар хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә алынган имгәнүдән (яралан удан, җәрәхәттән, контузиядән) яисә авырудан Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтеннән азат ителгән көннән алып бер ел эчендә үлеп киткән очракта, һәлак булганнарның (үлгәннәрнең) гаилә әгъзаларына, тигез өлешләрдә, 3 000 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләнә, алга таба бу сумма гаепле затлардан түләттерелә.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең һәлак булган (үлгән) хезмәткәре өчен бер тапкыр түләнә торган пособие алырга хокуклы гаилә әгъзалары булып түбәндәгеләр санала:

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәре һәлак булган (үлгән) көнгә аның белән теркәлгән никахта булган хатыны (ире);

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәренең ата-анасы;

18 яшькә җитмәгән яки, 18 яшенә җиткәнче инвалид калган булса, бу яшьтән өлкәнрәк балалары, шулай ук мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә укый торган балалары – укуларын тәмамлаганчы, ләкин аларга 23 яшьтән дә артканчы түгел.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләре хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә алынган имгәнү (яралану, җәрәхәт, контузия) яки авыру аркасында хезмәткә яраксыз дип танылуга бәйле рәвештә хезмәттән вакытыннан алда азат ителү очрагында, аларга 2 000 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләнә, алга таба бу сумма гаепле затлардан түләттерелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 33-ТРЗ